КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 234

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруының алга таба таралуын кисәтү максатларында һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимы кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче; 2020 ел, 27 март, 223 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә, шул исәптән мәдәният һәм ял паркларында, сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда гражданнарның турыдан-туры катнашында ял итү, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү, шулай ук тиешле хезмәтләр күрсәтү рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. 2020 елның 28 мартыннан санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәгеләрнең эшләвен туктатырга:

а) сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары), ваклап сату базарлары (аларда урнашкан азык-төлек товарларын ваклап сатуны гамәлгә ашыручы сәүдә объектларыннан, даруханәләр һәм даруханә пунктларыннан тыш);

б) башка ваклап сату сәүдә объектлары, түбәндәгеләрнең эшләвеннән тыш:

даруханәләр, даруханә пунктларының;

азык-төлек товарлары сатучы объектларның;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 мартындагы б-762 номерлы боерыгы белән расланган беренчел кирәкле азык-төлек булмаган товарларның тәкъдим ителә торган исемлегенә кертелгән товарлар сатучы, гомуми мәйданы 100 кв.метрдан артык булган объектларның, шулай ук мобиль элемтә хезмәтләре күрсәтүгә шартнамәләр төзү гамәлгә ашырыла торган объектларның;

в) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү объектлары (гражданнарның мондый объектлар урыннарына йөрмичә үзләре белән алып чыгуга хезмәт күрсәтүдән, заказлар илтүдән тыш);

г) матурлык салоннары, СПА-салоннар, косметика, массаж салоннары, солярийлар, мунчалар, сауналар һәм мондый хезмәтләр күрсәтелә торган башка объектлар.

Чикләүләр товарларны сатып алучыга илтеп бирү шарты белән, шулай ук дистанцион ысул белән товарлар сатуга (Россия Федерациясе законнары белән ирекле рәвештә сату тыелмаган товарлардан тыш), шулай ук оешмалар урыннарында тиешле оешмалар хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүгә карата кагылмый.

3. 2020 елның 28 мартыннан санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр Татарстан Республикасы территориясендә шифаханә-курорт оешмаларында (шифаханәләрдә), ел әйләнәсе эшли торган шифаханә-сәламәтләндерү балалар лагерьларында урыннар броньлауны, гражданнар (хезмәт командировкаларында булган яки хезмәт максатларында юлда йөргән затлардан тыш) кабул итүне һәм урнаштыруны туктатырга.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән оешмаларга аларда урнаштырылган затларга карата:

аларга үз-үзеңне изоляцияләү өчен шартлар тудыруны һәм аларның яшәү вакыты тәмамланганга кадәр, яшәү вакытын озайту мөмкинлегеннән башка, кирәкле санитария-эпидемиология чаралары үткәрүне тәэмин итәргә;

аларның туклануын турыдан-туры әлеге затларның яшәгән биналарында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге саклау өлкәсендә күзәтчелек

итү федераль хезмәте аңлатмалары нигезендә оештырырга.

4. 2020 елның 30 мартыннан санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр түбәндәгеләрне туктатырга:

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү турында гаризалар һәм документлар кабул итүне;

гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны (тууны, үлүне дәүләт теркәвеннән, шулай ук гаилә законнары нигезендә аерым шартлар булганда никахлашуны дәүләт теркәвенә алудан тыш).

5. 2020 елның 30 мартыннан санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр түбәндәгеләрне йөкләргә:

а) 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, шулай ук бу карарның кушымтасында күрсәтелгән авырулары булган затларга яшәү (тору) урыннарыннан (гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаган очраклардан тыш) китмәүне. Әлеге чикләү эш бирүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча документы (белешмә кәгазе) булганда оешмалар һәм хакимият органнары эшләвен тәэмин итү өчен эш урыннарында булуы бик мөһим булган әлеге оешмалар һәм хакимият органнары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә кагылмый;

б) башка гражданнарга яшәү (тору) урыннарыннан китмәүне (ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очраклардан һәм гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаган, шулай ук бу карар нигезендә якында урнашкан, сатуы чикләнмәгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу урынына барган, яшәү (тору) урыныннан 100 метрдан артмаган ераклыкта йорт хайваннарын урамда йөрткән, калдыкларны якында урнашкан калдыклар җыю урынына кадәр чыгарган очраклардан тыш).

Әгәр дә законнар нигезендә туктатылмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле булса, Татарстан Республикасы территориясендә хәрәкәт итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган форма буенча эш бирүченең документы (белешмә кәгазе) булганда рөхсәт ителә;

в) гражданнарга башка гражданнар белән бер-берсе арасында, шул исәптән җәмәгать урыннарында һәм җәмәгать транспортында (җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәткән очраклардан тыш) кимендә 1,5 метр дистанция (социаль дистанция) саклауны;

г) хакимият органнарына, оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук эшчәнлекләре гражданнар белән бергә булуга бәйле башка затларга гражданнарның (шул исәптән эшчеләренең) тиешле территориядә (аның янындагы территорияне дә кертеп), шул исәптән биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда (андагы урыннарда) махсус сызыклар сызу һәм аларга керү һәм аларда булуның махсус режимын билгеләү юлы белән социаль дистанция саклавын тәэмин итүне;

д) чит ил дәүләтләре территориясеннән кайткан гражданнарга:

беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә, медицина оешмаларына бармыйча, өйдә медицина ярдәме күрсәтүне сорап, кичекмәстән мөрәҗәгать итүне;

өйдә изоляция режимын саклауны;

е) чит ил дәүләтләре территориясеннән кайткан гражданнар белән изоляцияләүне тәэмин итү чорында бергә яшәүче затларга 14 календарь көн эчендә өйдә үз-үзеңне изоляцияләүне тәэмин итүне.

Бу пунктның беренче – өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләр медицина ярдәме күрсәтү очракларына, гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм башка хокукларын һәм ирекләрен яклауга турыдан-туры юнәлдерелгән гамәлләр, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы тору, җәмәгать тәртибен, милекне саклау һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү өлешендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча органнар һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү органнары, башка органнар эшчәнлегенә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләгән тәртиптә бирелгән махсус рөхсәтнамәләре булган очракта гражданнарга кагылмый.

6. 2020 елның 30 мартыннан санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр паркларга, урман паркларына керүне һәм аларда булуны тыярга. Әлеге тыю әлеге объектларга хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләренә кагылмый.

7. Оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә:

тәмәке тарту өчен кальяннар бирү буенча хезмәтләр күрсәтүне, кальяннар куллануны рөхсәт итмәскә;

эшчеләргә өйдә үз-үзеңне изоляцияләү режимын саклауны тәэмин итүдә булышлык күрсәтергә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән сорау кергәндә хезмәт функцияләрен башкаруга бәйле рәвештә коронавирус йогышлы авыруы белән авыручының барлык контактлары турындагы мәгълүматны кичекмәстән тапшырырга, авыручының эш урыннарын һәм бина урыннарын дезинфекцияләүне үткәрүне тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә:

хезмәткәрләр арасында коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау буенча кирәкле чаралар күрергә;

ял итү өчен яки шәхси хәлләр буенча Россия Федерациясе чикләреннән чыккан хезмәткәрләр чит илләрдән кайткан очракта, аларга эштә эшләргә рөхсәт итмәскә һәм Россия Федерациясе территориясенә кайткан көннән 14 календарь көн эчендә үз-үзеңне изоляцияләү кирәклеге турында кисәтергә;

корреспонденция кабул итүне һәм җибәрүне бары ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы, электрон һәм почта элемтәсе аша гына гамәлгә ашырырга.

9. 2020 елның 1 апреленнән санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр:

муниципальара пассажирлар йөртү һәм багаж ташу гамәлгә ашырылмый;

Татарстан Республикасыннан йөкләр җибәрүгә бәйле ташулар, Татарстан

Республикасы чикләрендә йөк ташулар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча җибәрүче оешма биргән белешмә кәгазе булганда гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

амбулатор һәм стационар медицина ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыручы, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының көчле вируслы йогышлы авырулар симптомнары, шул исәптән хастаханәдән тыш пневмония белән авыручыларны кабул итүгә һәм аларга кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүгә, коронавирус йогышлы авыруына тикшеренүләр үткәрү өчен һәм күрсәткечләр буенча авыручылардан биологик материал алуга әзерлеген тәэмин итәргә;

медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында вируска каршы препаратлар, шул исәптән коронавирус йогышлы авыруын дәвалау өчен тәкъдим ителгән препаратларның, дезинфекцияләү чаралары һәм индивидуаль саклану чараларының кимеми торган запасларын булдыруны тәэмин итәргә;

коронавирус йогышлы авыруы буенча имин булмаган территорияләрдән кайткан барлык гражданнарны 14 календарь көнгә көн саен медицина күзәтүендә тотуны оештырырга;

респиратор авыруларның беренче симптомнары барлыкка килгәндә медицина ярдәме күрсәтү өчен үз вакытында мөрәҗәгать итү кирәклегенә аерым игътибар биреп, халык белән гриппны, көчле вируслы йогышлы авыруларны, коронавирус йогышлы авыруын, хастаханәдән тыш пневмонияләрне профилактикалау турында аңлату эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советына Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау буенча нәтиҗәле чаралар күрергә.

12. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Татарстан Республикасы территориясендә коронавирус йогышлы авыруының Татарстан Республикасына керүен һәм таралуын булдырмау буенча эпидемиягә каршы чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә коронавирус йогышлы авыруының Татарстан Республикасына керүен һәм таралуын булдырмау буенча чаралар күрүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына булышлык күрсәтүне;

Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, шәхси саклау оешмаларына бу карарның

2 нче пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә эшләре туктатылган объектларның сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне.

13. «Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесенә даруханә челтәрендә вируска каршы препаратлар, шул исәптән коронавирус йогышлы авыруын дәвалау өчен тәкъдим ителгән препаратларның, дезинфекцияләү чаралары һәм индивидуаль саклану чараларының кимеми торган запасын булдыруны тәэмин итүне оештырырга.

14. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау буенча үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

15. Бу карар белән билгеләнгән тыюларның һәм чикләүләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе, шулай ук мондый тыюларның һәм чикләүләрнең үтәлешен тәэмин итү тәртибе, шул исәптән аларны бозуларны кисәтү буенча чаралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 30 март, 234 нче
карары редакциясендә)

Үз-үзеңне изоляцияләү режимын саклауны таләп итә торган авырулар исемлеге

1. Эндокрин системасы авыруы – E10 диагнозы буенча Халыкара авырулар классификациясе – 10 (МКБ-10) нигезендә классификацияләнә торган инсулинга бәйле шикәр авыруы.

2. Түбәндәгеләр арасыннан сулыш органнары авырулары:

2.1. J44 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган башка хроник обструктив үпкә авыруы.

2.2. J45 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган астма.

2.3. J47 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган бронхоэктатик авыру.

3. Кан әйләнеше системасы авыруы – I27.2, I27.8, I27.9 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган үпкә авырулары аркасында йөрәк һәм үпкә кан әйләнеше бозылулары авыруы.

4. Z94 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган трансплантацияләнгән органнар һәм тукымалар булу.

5. Сидек юлы системасы авыруы[1] – 18.0, 18.3 – 18.5 номерлы диагнозлар буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган 3 – 5 стадиядәге бөерләрнең хроник авыруы.

6. Түбәндәгеләр арасыннан яңа шеш авыруы[2]:

6.1. C00 – C80, C97 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган теләсә нинди локализацияләүдәге, шул исәптән мөстәкыйль күп санда локализацияләүдәге яман шеш авыруы.

6.2. C81 – C96, D46 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган кискен лейкозлар, яман шеш авыруы югары дәрәҗәдә булган лимфомнар, рецидивлар һәм башка лимфопролифератив авыруларның резистент формалары, хроник акселерация һәм бласт кризы фазаларындагы хроник миелолейкоз, беренчел хроник лейкозлар һәм лимфомнар[1].

---

[1]Үз-үзеңне изоляцияләү режимында төп авыру белән медицина оешмасына бару рөхсәт ителә.

[2]Үз-үзеңне изоляцияләү өченче клиник төркемгә кертелгән пациентларга кагылмый (онкологиядә).

---